Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Сәрдекбаш авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

2022 елның «11» ноябре № 7

**Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Югары Китәк поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 24 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Югары Китәк поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Китәк поселогы, Яңа урам, 2а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге Югары Китәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан; 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү: янгын гидрантларын урнаштыру, янгын сүндерү инвентаре сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсуслаштырылган машинаны карап тоту, янгын сүндерү техникасын тоту чыгымнары; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Югары Китәк поселогы урам юл челтәрен карап тоту;
- Югары Китәк поселогы зиратын карап тоту буенча эшләрне оештыру, зират өчен җиһазлар һәм инвентарьлар сатып алу; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- видеокүзәтү сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту;

- Югары Китәк поселогында урамнарны яктыртуны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Югары Китәк поселогы территориясен төзекләндерүне оештыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Югары Китәк поселогына балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Югары Китәк поселогында су башнясын ремонтлау һәм карап тоту, артезиан скважинасы өчен насос сатып алу; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Байлангар авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сардекбаш авыл җирлеге башлыгы И.М. Нәбиев

ОГРН 1021607752858
ИНН 1623001854